**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26 май 2026 ел № 588

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль контроль чараларын уздыруга җәлеп ителәә торган экспертларны аттестацияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 23 маендагы 549 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Норматив хокукый актларны «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә таләпләр турында» 2016 елның 26 мартындагы 236 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль контроль чараларын уздыруга җәлеп ителәә торган экспертларны аттестацияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 23 маендагы 549 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган муниципаль контроль чараларын уздыруга җәлеп ителәә торган экспертларны аттестацияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«Төзелгән гарызнамәне формат-логик тикшерү органы (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче гарызнамәнең электрон рәвешендәге һәр кырын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал сорауның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры сорауның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителәә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе җаваплылыгында калдырырга.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин